МИНИСТЕРСТВО
ЗЕМЕЛЬНЫХ И
ИМУЩЕСТВЕННЫХ
ОТНОШЕНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ
МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

20.04.2022 Казан ш. № 1221-р

Татарстан Республикасы Питрәч, Югары Ослан муниципаль районнары, «Казан шәһәре» муниципаль районы территорияләрендә газ бүлү челтәре объектларының саклык зоналарын урнаштыру турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, “Күчемсез милекнең дәүләт теркәве турында” 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль законның 32 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Инженерные решения» ҖЧҖ мөрәҗәгатьләре нигезендә, «Татарстан Республикасы пространство мәгълүматы фонды» ДБУ хатларын истә тотып (24.03.2022 № 511/04, 507/04, 513/04, 512/04, 07.04.2022 № 618/04), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Газ бүлү челтәре объектының («Кощаковский» җәнлек заводының көнъяк-көнчыгышында торак комплексын газ белән тәэмин итү» объектының саклык зонасы») саклык зонасын, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, гомуми мәйданы 28409 +/- 1475 кв.м.лы территория рәвешендә урнаштырырга.

2. Газ бүлү челтәре объектының («Кощаковский» җәнлек заводының көньяк-көнчыгышында торак комплексын газ белән тәэмин итү» объектының

саклык зонасы» 98,0 га. Уч., СНТ «Березка», «Архитектор», «Тверетиновка») саклык зонасын, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, гомуми мәйданы 1509 +/- 27 кв.м.лы территория рәвешендә урнаштырырга.

3. Газ бүлү челтәре объектының («Татарстан Республикасы Югары Ослан районы «Солнечная долина» ДНТ торак йортларын газ белән тәэмин итү» объектының саклык зонасы») саклык зонасын, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, гомуми мәйданы 14028 +/- 41 кв.м.лы территория рәвешендә урнаштырырга.

4. Газ бүлү челтәре объектының («ТР Казан ш. Константиновка ав.ның «Бахчисарай» коттеджлар бистәсе торак йортларын газ белән тәэмин итү системасының саклык зонасы») саклык зонасын, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, гомуми мәйданы 18041 +/- 47 кв.м.лы территория рәвешендә урнаштырырга.

5. Газ бүлү челтәре объектының («1 нче чиратта газ белән тәэмин итү тышкы челтәрләре» саклык зонасы») саклык зонасын, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, гомуми мәйданы 33544 +/- 64 кв.м.лы территория рәвешендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның 1 – 5 пунктларында күрсәтелгән газ бүлү челтәрләре объектының саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җир ресурслары идарәсе башлыгы Н.В. Захаровка йөкләргә.

**Министр в.б.** **А.И.Галиев**